КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 июль г.Казань № 596

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2009 ел, 29 март, 242 нче карары белән расланган 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2009 ел, 29 март, 242 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 59 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V бүлектә:

унтугызынчы абзацта «бары тик тотыла» сүзләрен «түбәндәгеләргә тотылырга мөмкин» сүзләренә алыштырырга;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортларда, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 нче пунктында күрсәтелгән торак йортларда (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган күпфатирлы йортларда) торак урыннар сатып алуга һәм мондый йортлар төзүгә, шул исәптән социаль файдалануга бирү шартнамәсе, яки социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын

файдалануга бирү шартнамәсе, яки, авария хәлендәге торак фондыннан күченүгә бәйле рәвештә, маневр фондының торак урынын файдалануга бирү шартнамәсе, яки авария хәлендәге торак фондының торак урыны милекчесе белән алмашу шартнамәсе буенча гражданнарга алга таба торак урыннар бирү максатларында;»;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«милкендә авария хәлендәге торак фондына керә торган торак урыннары булган гражданнарга Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлеше нигезендә алына торган торак урыннарын каплау өчен түләүгә.»;

егерме икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин